**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ДҮРТ-МУНЧА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

**№138** **07.12.2018 ел**

**«Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, сайланулы вазыйфаи затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең, белгечләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 23 апрелендәге 107 номерлы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

"Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында" 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, сайланулы вазыйфаи затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең, белгечләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 23 апрелендәге 107

номерлы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 2 пунктның 2.11 пунктчасында «38,75» санын «56» санына алмаштырырга.
2. «Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, сайланулы вазыйфаи затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең, белгечләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 23 апрелендәге 107 номерлы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 23 ноябрендәге 131 номерлы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Дүрт-Мунча авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
4. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Р.Т.Ситдыйков**